ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ БАЙСАР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

423745, Иске Байсар авылы,
Мәктәп ур., 44а йорт.
Тел.3-44-53

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА СТАРОБАЙСАРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

423745, село Старое Байсарово,
ул. Школьная,дом 44а,
Тел. 3-44-53

КАРАР
09 ноябрь 2020 ел

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№1

Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Иске Байсар авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Иске Байсар авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге Чиялек авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нчы елның 20 ноябре 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

1.1. Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге Чишмәбаш авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нчы елның 20 ноябре 12 сәгать 00 минутка билгеләргә.

1.2. Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге Яңа Байсар авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нчы елның 20 ноябре 14 сәгать 00 минутка билгеләргә билгеләргә.

1.3. Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге Иске Байсар авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нчы елның 20 ноябре 18 сәгать 00 минутка билгеләргә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

-Җирлектәге, җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларның эшчәнлеген тәэмин итү:
-юлларны төзекләндерү һәм карау;
җирлек халкын су, газ, электр, җылылык, ягулык белән тәэмин итү һәм суны чыгару өчен:
- су үткәргечләрен төзекләндерү, җирлектәге чишмәләрне рәсмиләштереп лизенция алу;
-җирлекне төзекләндерүне оештыру өчен:

- җирлектә беренчел янгын сүндерү чараларын тәэмин итү;
- җирлектә тарихи истәлекләрне саклау, файдалану һәм таныту:
- җирлек халкына ял итү урынын булдыру һәм шартлар тудыру;
- җирлектә һәм Яңа Байсар авылында стеллалар урнаштыру;

- Иске Байсар һәм Чишмәбаш авылы арасындагы Сөн елгасы аша салынган басмага ремонт үткәрү;

-җирлектә ритуаль хезмәт оештыру һәм зиярәтләрны тәзекләндерүне

"ӘЙЕ" "ЮК"

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Чиялек авылы, Алкаби урамы, 12 йорт, Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Чишмәбаш авылы, Узәк урамы, 28 йорт, Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Яңа Байсар авылы, Тегермән урамы, 11 йорт,Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Иске Байсар авылы, Совет урамы, 25 йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Иске Байсар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Кадыйров.Р.М.